Министерство образования и науки Российской Федерации
Федеральное государственное автономное образовательное
учреждение высшего профессионального образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»
ОГРН 1021602841391
Институт психологии и образования
Приволжский межрегиональный центр
повышения квалификации и профессиональной переподготовки
работников образования
Оренбургский тракт ул., д.4а, Казань, 420059
Тел.: (843) 233-70-40, факс: (843) 277-75-23
email: P.Mcdpo@ksu.ru

№ 0.1.2202.03-19/469/14 от 18.03.14
На № _____ от _____

Татарстан Республикасы
муниципаль районнары
башкарма комитетларының
мәгариф идарәләре һәм бүлекләре
җитәкчеләренә

І Республикакүләм Марсель Галиев укулары
үткәрү турында

Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге, Татарстан Республикасы язучылар Союзы, Азнакай муниципаль районының мәгариф бүлеге **2014 елның 28 апрель көнне** "Азнакай шәһәре гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә **І Республикаләм Марсель Галиев укуларын** үткәрә!

Марсель Галиев укуларының бурычлары:

- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру;
- Татарстанның халык язучысы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты, прозаик һәм шагыйрь Марсель Галиев иҗатын өйрәнү;
- укытучыларның фәнни-тикшеренү күнекмәләрен камилләштерү;
- укучыларда тикшерү, коммуникатив хәбәрдарлык формалаштыру, телебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт, фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү;
- белем бирү оешмаларының фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнү тәҗрибәсен өйрәнү, тәҗрибә уртаклашу;
- югары уку йортларында эшләүче галимнәрне һәм язучыларны укытучылар һәм укучылар белән эшчәнлеккә тарту.

І Республикакүләм Марсель Галиев укуларында катнашучылар турында мәгълүмат һәм аларның фәнни эшләре Ilgiza.Ilyasova@edu.tatar.ru адресына 2014 елның 5 апреленә кадәр җибәрелә.

Казан федераль университеты
Идел буе төбәкара мәгариф
хезмәткәрләренең квалификациясен
күтәрү һәм яңадан
әзерләү үзәге директоры **Р.Ф.Шәйхелисламов**